# ИСӘНМЕСЕЗ УКУЧЫЛАР!

# Хәерле көн!

# Имин үтсен көнегез!

# Сыйфат

Предметның

**билгесен**

белдерә.

**Нинди? Кайсы?**

сорауларына

җавап бирә.

**Сыйфатлар**

**исемгә**

бәйләнеп

килә.

**Сыйфатлар**

сөйләмне матурлыйлар. Алар предметларны, күренешләрне төрле яктан сурәтлиләр.

MyShared

# Сыйфатларны кем табар?




MyShared

# Сыйфат

асыл


нисби

# Сыйфат дәрәҗәләре

- төп — **ак, сары, матур**
- чагыштыру — **аграк, сарырак, матуррак**
- артыклык — **ап-ак, сап-сары,бик матур**
- кимлек — **аксыл, саргылт, -**




| гади дәрәҗә | чагыштыру дәрәҗәсе | артыклык дәрәҗәсе | кимлек дәрәҗәсе |
|---|---|---|---|
| | | | |



# Бирем

***Ак, күңеллерәк, ап-ак, кышкы, кызурак, көләч, кызгылт, юмарт, төчкелтем, ямь-яшел, дөм караңгы, сусыл, томса, бик матур, яктырак.***



| гади дәрәҗә | чагыштыру дәрәҗәсе | артыклык дәрәҗәсе | кимлек дәрәҗәсе |
|---|---|---|---|
| *ак*<br>*кышкы*<br>*көләч*<br>*юмарт* | *күңеллерәк*<br>*кызурак*<br>*яктырак* | *ап-ак*<br>*ямь-яшел*<br>*дөм караңгы*<br>*бик матур* | *кызгылт*<br>*төчкелтем*<br>*сусыл*<br>*томса* |



Синоним



Антоним



| Синоним сыйфатлар | Антоним сыйфатлар |
| --- | --- |
| **матур,**<br>***әдәпле,***<br>***авыр,*** | ***матур-***<br>***зур-***<br>**авыр-**<br>**кыю-** |

| Синоним сыйфатлар | Антоним сыйфатлар |
|---|---|
| ***матур, чибәр, сылу, гүзәл*** ( кыз)<br>***әдәпле,тәрбияле, тәртипле (бала)***<br>***авыр, кыен, читен, катлаулы (мәсьәлә)*** | ***матур- ямьсез***<br>***зур – кечкенә***<br>***авыр- җиңел***<br>***кыю-кыюсыз*** |

# Синоним сыйфатлар

**Мәгънә төсмерләре үзгә булса да , бер үк төрле билгене берничә сыйфат белән белдереп була. Андый сыйфатлар мәгънәдәш яки синоним сыйфатлар дип атала.**


Антоним сыйфатлар
Мәгънәләре буенча предметның бер-берсенә каршы билгеләрен белдерә торган сүзләр антоним сыйфатлар дип аталалар. Мәсәлән: матур — ямьсез, эшчән — ялкау, батыр — куркак.

***Халык- художник ул. Ул хәтта табигатьнең иң назлы иркәсе, иң нәфис сәнгате- чәчәкләрне дә матуррак, чибәррәк, сөйкемлерәк итә.(Г.Әпсәләмов)***

***Егет яшь тә түгел, карт та түгел, боек та түгел, шат та түгел, биек тә түгел, тәбәнәк тә түгел, чирле дә түгел, сәламәт тә түгел икән. ( Ф. Яруллин)***

## Синоним сыйфатлар

*матуррак, чибәррәк, сөйкемлерәк*


## Антоним сыйфатлар

*яшь- карт, боек- шат, биек- тәбәнәк, чирле- сәламәт*



# Физкультминутка.

Гөл сабагы күренде
Һәм кояшка үрелде.
Тибрәнде талгын җилдә,
Сокланды гүзәл җиргә.
Буй-сыннарын турайтты,
Бик матур чәчәк атты.
Җәеп ефәк таҗларын,
Сипте хуш ис , назларын.







Бирелгән антоним сыйфатларны ачыклаучы исемнәр табарга

ак(...) – кара(...)
матур(...) - ямьсез(...)
тырыш(...) - ялкау(...)
калын(...) – нечкә(...)
киң(...) - тар(...)
якты(...) – караңгы(...)

ак кар – кара күмер
тырыш эшче - ялкау песи
калын китап – нечкә дәфтәр
киң юл - тар сукмак
якты көн - караңгы төн

# Тест

1. Сыйфатлар нәрсә белдерә ?

**а) предметны; б) предметның эшен; в) предметның билгесен;**

2. Сыйфатларга нинди сораулар куела ?

**а) кем? нәрсә?; б) нинди? кайсы?; в) нишли? нишләде?;**

3. Сыйфатлар нәрсәгә бәйләнеп килә ?

**а) исемгә; б) фигыльгә; в) кисәкчәләргә;**

4. ***Уңган*** сүзенә **синоним сыйфат** табыгыз:

**а) ялкау; б) шаян; в) өлгер;**

5. ***Салкын*** сүзенә **антоним сыйфат** табыгыз:

**а) кызыл; б) җылы; в) җәйге;**

MyShared

# Мәкальләр

***Турылыклы булып үлү ялганчы булып үлүдән яхшырак.***

***Тырыш эшкә тырышыр, ялкау ашка сырышыр.***

***Эшлекле таш күтәрә , эшлексез көн үткәрә.***

***Тәмле дә тел,***
***Тәмсез дә тел.***

Нәтиҗә:

Синоним һәм антоним сыйфатлар предметның билгесен белдерү өчен, мәгънә төсмерен ачык күрсәтү өчен кулланылалар, сөйләмне матурлыйлар

**ӨЙ ЭШЕ**

19нчы күнегү. Сыйфатлар кулланып, керпе турындагы хикәяне дәвам итәргә.

***Минем сезгә теләкләрем:***

***Сәламәт булыгыз!***

***Бәхетле булыгыз!***

***Кояш кебек балкыгыз!***

***Йолдыз кебек яныгыз!***

***Чишмә кебек саф күңелле булыгыз!***

***Күбәләкләр кебек шаян булыгыз!***

***Кырмыскалар кебек эшчән булыгыз!***

***Зур үсегез, чын кеше булыгыз!***





***Дәрестә катнашып, үз белемнәрегезне күрсәткәнегез өчен зур рәхмәт!***





